КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2026 ел, 7 апрель

г.Казань

№ 363

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясындагы $5^1$ пунктының 2 пунктчасы һәм «Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $3^{23}$ өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органнарына ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү өлешендә республика башкарма хакимият органнары турындагы нигезләмәләргә үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләр эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен эшләгәндә һәм раслаганда әлеге карарга нигезләнеп эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органнарына йөкләргә. Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен гомуми контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 7 апрель, 363 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре (алга таба – контроль субъекты, ведомство контроле) гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт казна, бюджет учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт нигезендә булдырылган Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениеләре (алга таба – контроль объекты) эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

1.2. Әлеге Тәртип түбәндәгеләрне гамәлгә ашырганда кулланылмый:

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт контролен (күзәтчелеген);

бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә финанс контролен;

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында контроль тотуны;

«Юридик затларның кайбер төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны;

хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар үтәлешен ведомство контролендә тотуны;

Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән контрольдә тотуның башка төрләрен.

1.3. Ведомство контроле предметлары:

контроль объектлары тарафыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары үтәлешен тикшерү;

контроль объектлары эшчәнлегендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм туктату;

контроль объектлары эшчәнлегенең аларның гамәлгә кую документларында каралган оештыру максатларына һәм эшчәнлек төрләренә туры килүе;

контроль объекты тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның Татарстан Республикасы мәгълүмат базаларында булган факттагы мәгълүматларга туры килүе;

контроль объектлары эшчәнлегендә тайпылышларны ачыклау (финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләренең план һәм факттагы күрсәткечләре нисбәте);

төп эшчәнлек төрләрен үтәмәгәндә (сыйфатсыз үтәгәндә) өстәмә эшчәнлек төрләрен, шул исәптән керем китерә торган башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруны тикшерү;

хезмәт күрсәтүгә (эш башкаруга) дәүләт йөкләмәсен башкару тулылыгы һәм сыйфаты, аның үтәлеше турында хисапларның тулылыгы, дөреслеге;

бухгалтерлык исәбен дөрес алып бару һәм бухгалтерлык хисабын дөрес төзү;

бюджет сметасы үтәлешен;

контроль объектлары турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру өчен рәсми сайтта контроль объекты эшчәнлеге турындагы мәгълүматның ачык булуын һәм аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү;

контроль субъектлары тарафыннан контроль объектларына тапшырылган вәкаләтләрне һәм (яки) функцияләрне контроль объектлары гамәлгә ашыру;

контроль объектларына беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт милкәтен саклап калу һәм билгеләнеше буенча файдалану;

дәүләт йөкләмәсенең үтәлешен тәэмин итү, башка максатлар өчен субсидияләр алу һәм аннан файдалану шартларын үтәү;

керем китерә торган эшчәнлек алып бару тәртибен, күрсәтелә торган хезмәтләргә (башкарыла торган эшләргә) бәяләр (тарифлар) куллану тәртибен үтәү;

контроль субъекты һәм башкарма хакимиятнең башка органнары тарафыннан аларның компетенциясе кысаларында кабул ителгән карарларның контроль органнары тарафыннан тиешенчә үтәлеше;

федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән башка таләпләр үтәлеше.

## II. Ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләре

2.1. Ведомство контроле контроль субъекты җитәкчесе карары буенча күчмә яки документар тикшерү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Контроль субъекты җитәкчесе карарында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

контроль субъектының исеме;

контроль субъекты хезмәткәренең (хезмәткәрләренең), шул исәптән төркем (комиссия) җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы;

тикшерү уздыруга вәкаләтле контроль субъекты затының (вазыйфаи затларының), шул исәптән төркем (комиссия) җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), вазыйфасы;

контроль объектының исеме, юридик адресы һәм (яки) эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны;

тикшерү уздыру нигезе;

тикшерүне башлау һәм тәмамлау даталары;

контроль предметы;

тикшерү формасы;

тикшерелә торган чор.

2.3. Күчмә тикшерү контроль объекты урнашкан урын буенча үткәрелә.

2.4. Документар тикшерү контроль субъекты урнашкан урын буенча, аның рәсми соравы нигезендә бирелгән финанс, бухгалтерлык, хисап документлары, контрактлар (шартнамәләр), шулай ук ведомство контроле предметына кагылышлы башка документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Тикшерүләр графигы контроль субъектының җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

Контроль субъектының җитәкчесе тарафыннан кичекмәстән тикшерү үткәрү таләп ителә торган түбәндәге очракларда контроль объектының планнан тыш тикшерүе билгеләнә:

контроль субъектына контроль объекты эшчәнлегенә карата шикаятьләр (мөрәҗәгатьләр) керү, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан контроль объекты эшчәнлегендә мөмкин булган хокук бозулар турында мәгълүмат керү;

әлеге Тәртипнең 2.16 пунктында каралган, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы белешмәләр контроль субъектына билгеләнгән вакытта тапшырылмау.

2.6. Контроль объекты җитәкчесенә үткәреләчәк тикшерү турында контроль субъекты җитәкчесе карары күчермәсен бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша җибәрү юлы белән тикшерү башланганга кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

2.7. Тикшерү үткәрү срогы 40 эш көненнән дә артык була алмый.

2.8. Ведомство контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле контроль субъектының вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

күчмә тикшерү гамәлгә ашырылган очракта, хезмәт таныклыкларын күрсәтеп, контроль объектының территориясенә, биналарына, корылмаларына керү;

персональ мәгълүматлар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, контроль объекты эшчәнлегенә бәйле фактларны билгеләү һәм (яки) раслау өчен кирәкле документларны таләп итү;

персональ мәгълүматлар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, фотога төшерү, видеога яздыру, документларның күчермәләрен алу;

үткәрелә торган тикшерү мәсьәләләре буенча кирәкле аңлатмалар алу;

профильле белгечләрне җәлеп итеп, тикшерү үткәрү максатларында кирәкле экспертизалар билгеләү (оештыру) һәм башка гамәлләр башкару;

контроль объекты эшчәнлеген документаль һәм (яки) фактик өйрәнү буенча чараларны үткәрү (оештыру);

үз компетенциясе кысаларында тиешле белешмәләргә ия булган вәкаләтле органнардан һәм оешмалардан, тикшерү үткәрү чорыннан артмаган мәгълүмат бирү срогын күрсәтеп, контроль объекты турында мәгълүмат соратып алу.

2.9. Ведомство контролен үткәрү нәтиҗәләре буенча түбәндәге белешмәләрдән гыйбарәт тикшерү акты төзелә:

тикшерү акты төзелгән дата һәм урын;

контроль субъекты исеме;

контроль субъекты җитәкчесе карарының датасы һәм номеры;

контроль субъектының тикшерү үткәргән вазыйфаи затының яки вазыйфаи затларының фамилиясе, инициаллары;

контроль объектының исеме, шулай ук контроль объекты җитәкчесенең, контроль объектының башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы;

тикшерү үткәрүнең датасы, озынлыгы һәм урыны;

тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән ведомство контролен гамәлгә ашырганда ачыкланган хокук бозулар турында белешмәләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр;

контроль объекты җитәкчесе, контроль объектының башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиленең тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында белешмәләр;

тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның имзалары.

2.10. Тикшерү акты ике нөсхәдә төзелә, тикшерү үткәргән барлык вазыйфаи затлар тарафыннан имзалана һәм тикшерү тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә контроль объекты җитәкчесенә җибәрелә. Контроль объекты җитәкчесе тикшерү актын алу турында тикшерү уздырган контроль субъектында кала торган тикшерү актына язып куя.

2.11. Тикшерү акты буенча фикер каршылыклары булса, контроль объекты җитәкчесе тикшерү актын алган көннән алып 15 эш көне эчендә контроль субъектына язма рәвештә фикер каршылыкларын (алга таба – фикер каршылыклары) кертә.

2.12. Контроль субъекты язма рәвештә фикер каршылыклары алынган көннән алып 10 эш көне эчендә фикер каршылыкларының нигезләнгән булуын карап тикшерә һәм контроль субъекты җитәкчесе тарафыннан раслана торган ике нөсхәдә язма бәяләмә төзи. Бәяләмәнең бер нөсхәсе әлеге срок эчендә контроль объекты җитәкчесенә җибәрелә, икенчесе тикшерү актына теркәлә.

2.13. Тикшерү үткәргәндә контроль объекты эшчәнлегендә хокук бозулар ачыкланган очракта, контроль субъекты тикшерү тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә контроль объекты җитәкчесенә әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән формиа буенча хокук бозуларны бетерү кирәклеге турында таләп (алга таба – таләп) җибәрә һәм таләпне үтәү срокларын күрсәтә.

2.14. Контроль объекты җитәкчесе таләп алынган көннән алып биш эш көне эчендә хокук бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар планы (алга таба – чаралар планы) эшләүне һәм раслауны оештыра. Контроль объекты җитәкчесе тарафыннан расланган чаралар планы күчермәсе раслаган көннән алып ике эш көне эчендә контроль субъектына җибәрелә.

2.15. Әгәр фикер каршылыклары контроль субъекты тарафыннан нигезсез дип танылган булса, чаралар планы контроль объекты тарафыннан тулысынча үтәлергә тиеш.

Әгәр әлеге Тәртипнең 2.11 пунктында каралган фикер каршылыклары нигезле дип танылса, контроль субъекты әлеге Тәртипнең 2.13 пункты нигезендә контроль объектына җибәрелгән таләпне гамәлдән чыгара, бу әлеге Тәртипнең 2.12 пунктында каралган бәяләмәдә чагылдырыла. Чаралар планы әлеге Тәртипнең 2.12 пунктында каралган бәяләмә алынган вакыттан биш эш көне эчендә, әгәр фикер каршы-

лыклары тулысынча нигезле дип танылса, гамәлдән чыгарылырга яисә, әгәр фикер каршылыклары өлешчә нигезле дип танылса, үзгәрешләрне исәпкә алып, төзәтелергә һәм контроль субъектына җибәрелергә тиеш.

2.16. Контроль объекты контроль субъектына таләптә билгеләнгән сроклар эчендә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында белешмәләр бирә.

2.17. Тикшерү актлары, шулай ук ведомство контролен үткәрү барышында алынган, формалаштырылган башка документлар һәм мәгълүмат (алга таба – тикшерү материаллары) контроль субъекты тарафыннан кимендә биш ел саклана.

2.18. Татарстан Республикасы исеменнән дәүләт мөлкәте милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы буларак Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы контроль субъектларыннан тикшерү материалларын соратып алырга хокуклы.

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тоту тәртибенә кушымта

Форма

______________________________
(контроль объектының тулы исеме)

______________________________
(урнашу урыны адресы)

Хокук бозуларны бетерү кирәклеге турында
таләп

________________________________________________________________
(контроль субъектының тулы исеме)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2026 ел, _________ _______ нче (нчы) карары нигезендә ведомство контролен гамәлгә ашыру барышында ачыкланган, ______________________________
(контроль объектын тикшерү акты реквизитлары)
тикшерү актында күрсәтелгән хокук бозуларны __________ кадәр срок эчендә
(дата)
бетерү кирәклеге турында хәбәр итә.

______________________________ /__________________ / ____________________________
(вәкаләтле вазыйфаи зат вазыйфасы) (имза) (вәкаләтле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

______________________________